Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Түбән Мактама бистәсе Советы

КАРАРЫ

№ 32 02 август 2021 ел

Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистәсе Советының 2012 елның 27 декабрендәге 119 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама ш.т. бистәсе" нең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 38 статьясы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 468-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Түбән Мактама бистәсе Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистәсе Советының 2012 елның 27 декабрендәге 119 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Түбән Мактама ш.т. бистәсе" нең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Түбән Мактама бистәсе Советының 2016 елның 16 октябрендәге 53, 2017 елның 27 сентябрендәге 94 , 2018 елның 26 сентябрендәге 135, 2019 елның 06 июнендәге 163, 2020 елның 25 мартындагы 183, 2021 елның 11 июнендәге 30 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) «Индивидуаль торак төзелеше» территориаль зонасының текст өлешендә (Ж-1):

- рөхсәт ителгән файдалануның төрле төрләреннән «гомуми мәйданы 150 квадрат метрдан артмаган беренче зарурлык товарлары кибетләре» төрен төшереп калдырырга,

- шартлыча рөхсәт ителгән куллану төрләренә «гомуми мәйданы 150 кв.м дан артмаган беренче зарурлык товарлары кибетләре» төрен өстәргә;

б) 30 статьяда 5 һәм 6 пунктларны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Комиссиягә әлеге Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кергән көннән соң, егерме биш көн эчендә Комиссия бәяләмә әзерли, анда Кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр яисә мондый тәкъдимне кире кагу турында тәкъдимнәр кертелеп, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, бәяләмәне Башкарма комитеты җитәкчесенә җибәрә.

6.Башкарма комитет җитәкчесе, Комиссия бәяләмәсендәге рекомендацияләрне исәпкә алып, әлеге Кагыйдәләргә үзгәреш кертү турында яисә, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, Кагыйдәгә үзгәреш кертү турында тәкъдимне кире кагу хакында проектны әзерләү турында карар кабул итә һәм бу карарның күчермәсен мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.»;

в) Шәһәр төзелеше регламентының 35 статьясы «Ж2. Күпфатирлы торак йорт төзелеше зонасы.» бүлегендә «Җир участокларының иң чик күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең иң чик параметрлары.» бүлеген түбәндәге бүлек белән тулыландырырга:

Җир участокларының иң чик күләмнәре һәм рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү түбәндәге таблица күрсәткечләренә туры килергә тиеш.

| Үлчәү берәмлекләре һәм параметрлары төрләре | | Күчемсез милекне файдалануның төп рөхсәт ителгән төрләренә карата параметрларның әһәмияте | |
|---|---|---|---|
| | | Блокланган йортта бер гаиләгә торак берәмлеге | Күпфатирлы йортлар 4 каттан да югары түгел |
| Җир кишәрлекләренең чик параметрлары | | | |
| Минималь мәйдан | кв.м | 400 | 600 |
| Урамның (юл )фронт буенча минималь киңлеге | м | 6 | 27 |
| Җир кишәрлекләре чикләрендә рөхсәт ителгән төзелешнең иң чик параметрлары | | | |
| Участок төзелешенең максималь проценты | % | 50 | 33 |
| Участок границасының алгы чигеннән төзелешнең минималь чигенү күләме (башка күрсәткеч төзелешне җайга салу сызыгы белән билгеләнмәгән очракта) | м | 3 | 3 |
| Участокның ян чикләреннән төзелмәләрнең минималь чикләре | м | а) 0 - күрше блокларга кушылган очракларда (брандмауэр диварлары мәҗбүри булганда) б) 3 - башка очракларда | 6 |
| Участокның арткы чикләреннән төзелмәләрнең минималь чикләре | м | 5 (төзелешне җайга салу линиясе башкасы билгеләнмәгән булса) | 6 |
| Бинаның максималь биеклеге | м | 12 | 16 |
| Җир кишәрлекләре киртәләренең максималь биеклеге | м | 1,2* | по махсус килештерү буенча * |

* Чиктәш участоклар арасындагы материал һәм киртә типлары, яшелчә бакчалары белән тәэмин ителгән өлештә, кояш нурларын үткәрә торган челтәрсыманнар кабул ителә.

2. Әлеге карарны Тихоновка авылы һәм Түбән Мактама ш.т. бистәсе торак пунктлар территориясендә урнашкан мәгълүмати стендларда игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Түбән Мактама шәһәр
тибындагы бистә башлыгы Р.А. Бәдретдинов